Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының егерме сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

8 декабрь, 2022 ел № 204

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов тарафыннан 2019-2021 елларда бирелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләрен карау турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгы урынбасары-хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия рәисен тыңлаганнан соң, 2019-2021 елларда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов тарафыннан бирелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләрен карап, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4 пунктының 4.5 пунктындагы 4.5 пунктчасына һәм «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 8 пунктына таянып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбовка кисәтү белдерергә.
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбовка муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата чикләүләрне һәм бурычларны үтәүне катгый рәвештә тәкъдим итәргә һәм коррупциягә каршы тору өлкәсендәге законнар таләпләрен бозуларны булдырмаска.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итү буенча даими комиссиягә, законлылык, хокук тәртибе һәм регламентка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов